# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18 март 2024 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 3 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 25.11.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 25.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә 2024 елның 18 мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:
“Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 25.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 25.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистартучы тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәте өчен, кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү))?”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 21 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 20.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 20, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

“Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 25.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 25.11.2023 №2 “2024 елда

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тархан торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистартучы тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәте өчен, кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү))?”.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Илбәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова